Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче
Яңа Баланда авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

Карар

№ 3 2021 елның 11 ноябре

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 - ФЗ Федераль закон 25.1, 56 статьясы нигезендә», «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Иске Үзи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы 24 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Советы «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 05.11.2019 ел, №105 карары нигезендә, 2021 елның 11 ноябрендәге Иске Үзи авыл җирлегендә Яңа Баланда авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда үзара салым кертүгә Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Баланда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә урамнарны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- юл полотносы урнаштыру (грунт күтәрү, авыл урамнарын ком һәм вак таш белән җәю)

- вак таш сатып алу;

2. ТКО җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛЫП КАЛДЫЛАР»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 21 граждан кертелгән. 14 гражданнар- җыенында катнашучыларның саны.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА»позициясе өчен 14 граждан тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде;

«ТЫЕЛЫП КАЛДЫЛАР» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Үзи авыл җирлегенең Яңа Баланда авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. Мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга: «2022 елда үзара салым кертүгә Аксубай муниципаль районының Иске Үзи авыл җирлеге Яңа Баланда авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә урамнарны кышкы карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу);

- юл полотносы урнаштыру (грунт күтәрү, авыл урамнарын ком һәм вак таш белән җәю)

- вак таш сатып алу;

2. ТКО җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу:

- контейнер мәйданчыклары төзү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Иске Үзи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә һәм Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Иске Үзи авыл җирлеге башлыгы Н.В.Айдова